**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «11» июленнән № 47-355

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, депутатларга хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, муниципаль норматив хокукый базаны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карары (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 35-282 номерлы, 2024 елның 23 маендагы 46-345 номерлы карарлары редакциясендә)(алга таба-Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 өлешнең 4 пунктында «вазыйфаи окладларның бер проценты» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:
«муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче аерым затларга, аларның гомуми эш нәтиҗәләренә шәхси кертемнәрен исәпкә алып, премия күләме арттырылырга мөмкин;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

https://pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырgahttps://pravo.tatarstan.ruhttps://novosheshminsk.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов